**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2023 № 1 Күләгәш авылы

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кулегаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 25 октябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 25 октябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 нче этап: Күләгәш авылы Яшьләр урамында, Лесная урамында, Казан урамында, Пионер урамында яшәүчеләр.

-2 нче этап: Күләгәш авылы Совет урамында, Спорт тыкрыгында яшәүчеләр

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен Күләгәш авыл җирлеге Күләгәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан,

студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен гсм һәм запас частьләр алу).

2. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру)ремонтлау.

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Пионер ур., Лесная ур., юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю)

4. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү (үләннәр һәм чүп үләннәр чабу; тракторны карап тоту һәм хезмәт күрсәтү; балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Күләгәш авылы, Совет урамы, 38 А йорты, авыл мәдәният йорты.

6. Күләгәш авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Кулегашского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы

В.А.Николаев